ЛЕНИНОГОРСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.05.2022 г.Лениногорск № 95

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 18 маендагы 63 номерлы карары белән расланган Шәһәр җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук шәһәр җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның хатыннары (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советы ның 2016 елның 18 маендагы 63 номерлы карары белән расланган Шәһәр җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук шәһәр җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның хатыннары

(ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

8 пунктның 3 пунктчасында «, акцияләр» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында http://leninogorsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры Р.Г.Хөсәенов